Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение

«Усть-Туркская средняя общеобразовательная школа» Бажуковский филиал

СОГЛАСОВАНО

Заместитель директора по УВР

_______/ Аитова Э.Р.

«31» августа 2023 г.

УТВЕРЖДЕНО

Директор МАОУ «Усть-Турк

_______/ Юсупова И.Ф.

Приказ №100 от

«31» августа 2023 г.

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

**курса внеурочной деятельности**

**«Занимательная грамматика татарского языка»**

для обучающихся 5го класса

**с. Бажуки, 2023**

## Аңлатма язуы

“Күңелле татар теле” түгәрәге программасы 5нче сыйныфта укучы балаларга татар телен тирәнтен өйрәнү өчен төзелде. Әлеге программа 34 сәгатькә исәпләнгән. Программа берничә теманы үз эченә ала. Аларның һәркайсында төрле эш формалары һәм ысуллары: лекция, семинар, әңгәмә, укучыларның мөстәкыйль, гамәли һәм иҗади эшләр кулланыла.

Программада тәкъдим ителгән темалар укучылар өчен кызыклы, аларны иҗади эзләнергә, фикер йөртергә өйрәтә, мәктәп программасының дәвамы була ала.

### *Түгәрәк программасының максаты*

Татар һәм рус тел белемен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәрнең эшчәнлеге турында кыскача мәгълүмат бирү. Дәрестә алган белемнәрне тирәнәйтү һәм киңәйтү, аларны тормышта гамәли куллана белү күнекмәләрен бирү.

Укучыларга татар һәм рус телләренең кайбер темаларын чагыштырып өйрәтү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, татар халык авыз иҗаты белән таныштыру, аларны өйрәнүдә милли төбәк компоненты куллану.

Дәүләт теле буларак татар теленең аралашу даирәсен киңәйтү, аның дәрәҗәсен күтәрү, телгә мөнәсәбәттә ихтирам тәрбияләү. Укучыларда җаваплылык хисе тәрбияләү, бер-береңә игътибарлы булуны, ярдәм итүне үзмаксат итеп кую.

### *Программаның бурычлары*

Татар һәм рус телләренең грамматикасының кайбер темаларын чагыштырып өйрәнүдә укучыларның интеллектуаль һәм гамәли белем-күнекмәләрен үстерү өчен шартлар тудыру.

Татар һәм рус телләрендә охшашлыкны һәм аермалыкны өйрәтү.

## Түгәрәкнең программасы

- укучыларның татар телен өйрәнүгә карата иҗади активлыкларын арттыру;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның киләсе үсешенә булышлык күрсәтү.
- дәрестә алган грамматик, орфографик, пунктуация, сөйләм теле һәм язу күнекмәләрен ныгыту һәм үстерү;
- иҗат эше белән шөгыльләнү һәм материалларны төрле басмаларга тәкъдим итү;
- төрле темаларага проектлар эшләү;
- мәктәп, район, районара күләмдә үткәрелә торган бәйгеләрдә катнашу;
- еллык эшкә йомгак ясау.

## Календарь тематик план

| **№** | **Курсның темасы** | **Сәг са ны** | **Вакыты** | **Эш формасы** | **Кулланылган эш ысуллары** |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш. Түгәрәк курсының эчтәлеге белән танышу. Куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру. | 1 | | әңгәмә | Кызыклы сораулар, тизәйткеч, башваткычлар чишү |
| 2 | “И минем җандай кадерле, татар телем!” | 1 | | әңгәмә | Туган тел турында мәкальләр ятлау |
| 3 | Күренекле татар тел галимнәре, тел белгечләре турында мәгълүмат бирү | 1 | | презентация | Тел турында язган шагыйрьләрнең шигырьләрен искә төшерү, китаптан уку |
| 4 | «Минем тормышымда туган телнең әһәмияте» темасына сочинение | 1 | | диалог | Сүзләр запасын туплау өстендә эшләү |
| 5 | Фонетика патшалыгына сәяхәт. | 1 | | уен | Авазларны һәм хәрефләрне таный, аера белү |
| 6 | Фонетик транскрипция | 1 | | практикум | Транскрипцияне белү |
| 7 | “Сузыклар һәм тартыклар интеллектуаль ярышы”бәйгесе | 1 | | уен-ярыш | Сузык һәм тартыкларның квалификациясен белү |
| 8 | Сингармонизм, аның төрләре. | 1 | | китап белән эш | Рәт һәм ирен гармониясенә карата үзбашка эш |
| 9 | [в ,w] тартыклары. Дифтонг. | 1 | | | Ярыш, уен, китап белән эш |
| 10 | Иҗек калыплары. Ачык һәм ябык иҗекләр. | 1 | | тактада эш | Үзбашка эш, чылбырлап уен |
| 11 | Фонетик уеннар | 1 | | уен | Төрле характердагы уеннар |
| 12 | Сүзләрне дөрес куллану һәм дөрес язу күнегүләре | 1 | | китап белән эш | Дөрес сөйләү, дөрес язуга күнегүләр |
| 13 | “Иң грамоталы язучы” конкурсы | 1 | | диктант | Грамоталылыкны тикшерүгә язма эш |
| 14 | Төрле сүзләрдә басымны билгеләргә өйрәнү | 1 | | уен | Чылбырлап тактада, урында эшләү |
| 15 | Графика. Язу ничек барлыкка килгән? | 1 | | лекция-әңгәмә | Реферат яклау |
| 16 | Алфавитта кемнәр яши? | 1 | | диалог-әңгәмә | Алфавитны яттан сөйләү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Без әкият язабыз | 1 | | БСҮ | Бирелгән тема буенча әкият чыгара, аны яза белү |
| 18 | Шарадалар һәм метаграммалар | 1 | | практикум | Шарадалар һәм метаграммалар чишү |
| 19 | Тестлар эшләү | 1 | | тикшерү-ныгыту | Тестлар эшләү |
| 20 | Сүзгә фонетик анализ ясау | 1 | | белемнәрне системалаштыру | Сүзгә фонетик анализ ясау |
| 21 | Лексика илендә | 1 | | әңгәмә | Реферат яклау |
| 22 | Синонимнар | 1 | | лексик домино уйнау | «Мин әйтәм, син әйт” уеннын уйнау |
| 23 | Антонимнар | 1 | | лексик домино уйнау | “Кара-каршы ярыш” уенын үткәрү |
| 24 | Омонимнар. | 1 | | лексик лото уйнау | “Кем күбрәк белә” уенын үткәрү |
| 25 | Мавыктыргыч фразеологизмнар. | 1 | | лекция | Җөмләләр төзү, сүзлекләр белән эшләү |
| 26 | Бер һәм күпмәгънәле сүзләр. | 1 | | әңгәмә | Сүзлек белән эшләү |
| 27 | Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр | 1 | | диалог | Китап белән эш, уеннар |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 28 | Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составы | 1 | | диалог-әңгәмә | Китап белән эш |
| 29 | Алынма сүзләрне аера белүгә күнегүләр | 1 | | практикум | Презентация карау, китап белән эшләү |
| 30 | Викторина «Сүзләр илендә». | 1 | | уен-ярыш | Төрле характердагы сорау-биремнәрне үтәү |
| 31 | Лексикография. Татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләре. | 1 | | сүзлекләр белән эш | Сүзлекләр белән эшләү |
| 32 | Без проект язабыз | 1 | | әңгәмә | Проект язарга өйрәнү, бергәләп проект язу |
| 33 | Бер темага проект язу | 1 | | үзбашка эш | Проект язу |
| 34 | Түгәрәк эшенә йомгак ясау | 1 | | әңгәмә -диалог | Эшкә нәтиҗә ясау |

**Көтелгән нәтиҗәләр**

- алган белемнәрен практикада куллану;

- төрле конкурс, интеллектуаль бәйге, олимпиадаларга әзерләнү һәм катнашу.

Программаның күләме укучылар үзләренең һөнәри омтылышларын, сәләтләрен ачыкларга, традицион булмаган дәрес төрләре аша матур сөйли, аралаша, үз фикереңне эзлекле, аңлаешлы итеп әйтеп бирүнең киләчәк тормышта бик кирәк булуына ышандыру өчен җитәрлек дип уйлыйм.